Рус мәктәбенең татар төркемендә укучы балалар өчен
татар әдәбиятыннан олимпиада биремнәре

7 нче сыйныф
Үткәрү вакыты 180 мин.

I. ТЕСТ:

1. **Әсәрләрнең жанрларын языгыз:** (1әр балл)

а) “Идегәй” _____
ә) “Матурлык” _____
б) “Алсу” _____

2. Җырларның төрләрен билгеләгез: (1әр балл)

а) “Сөмбелә” _____
ә) “Герман көе” _____
б) “Челтәр элдем читәнгә” _____

3. Әдәби жанрларны санап чыгыгыз: (1 жанр, 1 балл)

1._____
2. _____
3. _____
4. _____
5._____
6. _____

II. БИРЕМНӘР:

1. Дастан жанрының үзенчәлекләрен санагыз. Укыган дастаныгыз мисалында фикерегезне дәлилләгез (8 балл).

_____
_____
_____
_____
_____
_____
_____
_____
_____
_____
_____
_____
_____
_____
_____
_____
_____
_____
_____
_____
_____

2. Татар халкының нинди милли бәйрәмнәрен беләсез? Әлеге бәйрәмнең үткәрү шартлары, максаты хакында белгәннәрегезне языгыз (10 балл).

3. Бу юллар кайсы әсәрдән? Авторын, әсәрнең исемен языгыз. Төп геройны характерлагыз (10 балл).

Әнисе мич ягып җибәргәч, мич каршысына утырып, үзе белән алып кайткан бердәнбер китапны укый. Ул - «Советлар Союзының Бөек Ватан сугышы турында» дигән китап. Моны демобилизацияләнгән һәр кешегә Флотның Политидарәсе биреп җибәрә иде. Китапның титул битенә матшинкада басылган бер кәгазь ябыштырганар. Ул – Рушад исеменә.

«Икенче статья старшинасы, ВКП(б) члены агитатор Сулимовка. Кызыл Байраклы 4 нче Балтик Флотының Политидарәсе тыныч хезмәткә озатканда Сезгә бу китапны истәлек итеп тапшыра. Хәрби данга күмелгән Балтик флотында хезмәт иткәндәге кебек тыныч тормышта да алдынгы сафта булуыгызны Политидарә өмет итеп кала.

Даһи юлбашчыбызның бу хезмәте һәрвакытта да сезнең киңәшчегез булсын!»

Китапның эчендә тагын бер документ бар. «Хәрби Диңгез Флотыннан демобилизацияләнгән, университетның элекке студенты Рушад Сулимовны Акбалык урта мәктәбенә тарих укытучысы итеп билгеләргә». Копия дөрес... Әйе, дөрес...

Фашистларның су асты көймәләренә каршы сугышларда катнашып, торпедалар, дәһшәтле тирәнлек бомбалары белән очрашкан һәм Җиңү көнен Кенигсбергта каршы алган фронтовик Сулимовка бу приказны алганда нибары егерме яшь иде.

Сугышка барып фашистлар өерен күрермен дип ул башына да китермәгән иде.

Барлыгы: 40 балл.